**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 64 25 сентябрь 2017 ел.

Мәлбагыш авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мәлбагыш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Мәлбагыш авылы башкарма комитетының 2017 елның 11 сентябрендә чыккан 14 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендә чыккан 63 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте :

1. Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 2017 елның 19 ноябре көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Мәлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) авыл җирлегенә кергән торак пунктларда җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшләрен башкару :
- авыл билэмэсенэ кергэн торак пунктлардагы юлларга щебенка жэеп ремонтлау өчен;

2) авыл җирлеге биләмәсен төзекләндерү өчен ( урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнарга һәм йортларга урам исемнәре, йорт номерлары урнаштыру, кечкенэ архитектура формалары кую һәм төзекләндерү) :
-кышын авыл билэмэсенэ кергэн торак пунктлардагы юлларны кардан чистарту өчен;

3) халыкнын ялын оештыру һәм мәдәни оешмалар хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин иту өчен шартлар тудыру:

- бәйрәмнәр уздыру өчен;

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис И.А.Ахтямова